## 1. Текстны укы.

Бер йортта Песи белән Эт, Әтәч һәм Кәҗә яшәгәннәр. Кич белән алар ишек төбенә җыелалар да үзләренең эшләре турында сөйләшәләр икән. Сөйләшәләр дә бәхәсләшеп тә китәләр икән. «Кем нәрсә ярата? Нинди азык тәмлерәк?» дип бәхәсләшәләр икән.

— Иң тәмле сый,— сөт,— ди Песи.— Сөттән соң бер тычкан да тотып кабып җибәрсәң, бигрәк тә шәп була инде! Тик тычканны тотуы кыен.

— Сөт нәрсә? Ул бит сыек, тамак туйдырмый. Ә менә ярма бөртекләрен, солы орлыгын тук-тук итеп чүпләсәң — менә шунда тамак тук-тук-тук була! — ди Әтәч.

— Юк-юк! — дип сүзгә кушыла Акбай.— Бөртек чүпләп кенә туеп бул-бул-булмый. Менә сөяк кимерсәң, чынлап та әйбәт була, шунда ук тук буласың. Нинди азык тәмле, нинди азык файдалы икәнен миннән дә әйбәт белгән хайван юк.

— Нәрсә-ә-ә сөйлисең син,— дип каршы килә Кәҗә.— Менә кәбестә-ә-ә булса икән. Иң тәмле азык — кәбестә-ә-ә! — Ди ул.

Алар бәхәсләшәләр икән әле — һаман килешә алганнары юк,

Биремнәрне үтә:

**1.Бу текстка нинди исем туры килә?**

а) Кем кайда яши? б) Кем нинди төстә?

в) Кем нәрсә ярата? г) Кем укырга ярата?

**2. Бу йортта нинди хайваннар яшәгән? Шул сүзләр астына сыз:**

Тавык, Песи, Төлке, Бүре, Эт, Куян, Сыер, Әтәч, Сарык, Ат, Кәҗә.

**3. Хайваннар кайсы вакытта бәхәсләшәләр?**

а) иртә белән б) көндез в) кич белән г) төнлә

**4. Хайваннар нәрсә турында бәхәсләшәләр? Текстта шул җөмләне табып, астына сыз.**

**5. Хайваннарның бәхәскә керү тәртибен яз:**

1. ________________ 2. ______________
3.________________ 4. ______________

**6. Тексттагы кайсы хайванның кушаматы Акбай?**

а) Тавык б) Песи в) Куян г) Эт д) Әтәч

7.

а) Кәҗә нәрсә ярата? ___________________________________________

б) Эт нәрсә ярата? ___________________________________________

**8. Кайсы хайван ярма бөртеге белән солы орлыгы ярата?**

а) Тавык б) Песи в) Куян г) Эт д) Әтәч

**9. Әтәч нинди азык яратмый?**

а) ярма бөртеге б) сөт в) солы орлыгы

**10. Әтәч уйлавынча ни өчен сөт тамак туйдырмый? Ул ....**

а) салкын б) сыек в) салкын г) тәмсез

**Бәяләү өчен ачкыч**

| Бирем саны | Дөрес җавап | Балл |
|---|---|---|
| 1 | в) Кем нәрсә ярата? | 2 балл |
| 2 | Песи, Эт, Әтәч, Кәҗә, | 2 балл (4 хайван исеме дә дөрес сайланган), 1 балл (1 хата киткән: 3 хайван гына күрсәтелгән, яисә текстта булмаган 1 хайван сайланган (3 се дөрес сайланган булырга тиеш) |
| 3 | в) кич белән | 1 балл |
| 4 | «Кем нәрсә ярата? Нинди азык тәмлерәк?» дип бәхәсләшәләр икән. | 2балл (Җөмлә астына тулысынча сызылган), балл (Җөмлә табылган, ләкин тулысынча сызылмаган) |
| 5 | 1.Песи 2. Әтәч 3. Эт 4. Кәҗә | 1 балл |
| 6 | г) Эт | 1балл |
| 7 | а) кәбестә<br>б) сөяк | 2 балл ( һәр дөрес җавапка – 1 балл) |
| 8 | д) Әтәч | 1 балл |
| 9 | б) сөт | 1 балл |
| 10 | б) сыек | 1 балл |

Баллар буенча билге кую:
13-14 балл – “5”
10-12 балл - “4”
7-9 балл – “3”
0-6 балл - “2”